ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 27 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 44 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^7$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$10^7$ статья. **Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү**

Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукы вакытлыча чикләнергә мөмкин.

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кабул ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 07 октябрь
№ 75-ТРЗ